УДК 94(47)

*З.Р. Хәбибуллина*

# БАШКОРТСТАНДА МӨСЕЛМАННАРНЫҢ «ИЗГЕ УРЫННАР»Ы (1944–1965 еллар)

В статье на основе материалов Центрального исторического архива Республики Башкортостан (1944–1965 гг.) рассматривается бытование религиозной практики посещения захоронений аулия – «святых» – среди советских мусульман и деятельность Уполномоченного Совета по делам религиозных культов при Совете Министров СССР по борьбе с ней.

**Ключевые слова:** ислам, паломничество, аулия, святые места, уполномоченный, БАССР.

Башкортстан Республикасы мөселман халкы арасында күренекле дин әһелләре җирләнгән урыннарга зиярәт кылу кебек дини традицияләрнең бүген дә саклануы һәм аның тагын да киңрәк тарала баруы тарихи күзлектән караганда да, бу өлкәгә дәүләт сәясәте контекстында да фәнни кызыксыну уята. Башкортстан Республикасы Үзәк тарихи архивындагы Р-4732 нче фонд, СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет материалларына нигезләнеп әзерләнгән бу мәкаләдә мөселманнарның изге саналган урыннарга мөнәсәбәтенә карата әлеге Совет һәм аның БАССРдагы Вәкиллеге эшчәнлеге яктыртыла.

Күрсәтелгән еллар дәвамында илдәге дини тормыш 1944 елның 19 маенда оештырылган Дин эшләре буенча Совет күзәтчелегенә алына. Бу Советның төп максаты диннәргә мөнәсәбәттә Совет дәүләте сәясәтен тормышка ашыру, дини йолалар турындагы закончалыкларның үтәлешен контрольдә тоту була. Регионнарда дини проблемаларны хәл итү өчен Совет тарафыннан урыннарда вәкилләр билгеләнә. Аларның мәгълүмати хисап-хәбәрләрен илнең дини берләшмәләргә карата куелган сәяси һәм гамәли юнәлешләре нигезендәге документлар тәшкил итә, шулардан чыгып, СССРда дини эшләрнең тормышына бәя бирелә. Шуңа күрә урыннардан алынган мәгълүматлар илдәге дини йолаларның үтәлеше, аларның халык массасына йогынтысы, гамәлдәге законнарның аларга карата дөрес кулланылуы һ.б. хакындагы картинаны чагылдыралар. СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет белән БАССРдагы аның Вәкиллеге арасындагы үзара язма документлар, дин тотучыларны һәм руханиларны кабул итү беркетмәләре, шулай ук Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең (ДУМЕС) мөселманнарга ачыктан-ачык җиткерелгән документлары илдә исламның ролен, дин тотучылар белән руханиларның теләк-омтылышларын күзалларга мөмкинлек бирә, хакимиятнең җирле органнары тарафыннан оештырылган чараларның

төрләре һәм нәтиҗәләре хакында мәгълүмат җиткерә.

Дин эшләре буенча Советның күзәтү һәм контрольдә тоту пунктларынең берсе – изге урыннарга табыну йолаларын үтәү була. Аңа даими җиткереп барыла торган мәгълүмати белешмәләрдә Башкортстан АССР территориясендәге мөселманнар өчен изге саналган каберлек-төрбәләрнең урыннары һәм аеруча күренекле ислам эшлеклеләренең исемнәре күрсәтелергә, шулай ук ул урыннарга күмәкләп зиярәт кылулар һәм аларның ешлыгы (ел дәвамында яки билгеле бер вакытта) хакында да хәбәр ителергә тиеш була [Переписка с Советом... 1944–1945 гг., л. 24]. 1947 елда СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет БАССР вәкиллегенә М. Кәримовка түбәндәге телеграмманы җибәрә: «Вам следует собрать следующие сведения: о паломничестве в мазары (гробницы), где похоронены выдающиеся деятели ислама. Если эти паломничества имеют место, то Вам необходимо выявить и составить краткий перечень важнейших существующих в БАССР мазаров (гробниц) с кратким описанием их. При составлении перечня Вы можете посоветоваться с муфтием Расулевым, членами Духовного управления или муллами зарегистрированных мечетей» [Переписка с Советом... 1947 г., л. 8].

Мөселманнарның табыну урыннары турындагы мәгълүматлар гадәттә Вәкиллек отчетының «Сектантлар хәрәкәте» бүлегенә урнаштырыла. БАССР территориясендә ике урынга – исламның күренекле эшлеклеләре Хөсәен бәк (Чишмә районы) һәм Җәгъфәр ишан (Дәүләкән районының Тимәш (Тимашово) авылы) җирләнгән урыннарга зиярәт кылу киң таралган. Хөсәен бәк каберенә кирпичтән манара (мавзолей) эшләнгән һәм аңа «Монда Хөсәен бәк җирләнде. 1053 ел» дип язылган, әмма аның ислам эшлеклесе буларак күрсәткән хезмәтләре ачык билгеле түгел, шуңа да карамастан, дини йолаларны үтәүче мөселманнар аны «изге» санап, каберенә зиярәт кылуны дәвам итәләр. Вәкиллек мәгълүматларына караганда, Җәгъфәр ишан каберенә табыну тенденциясе әле дә бик көчле [Переписка с Советом... 1950 г., л. 12, 20]. Изге урыннарга табынуны контрольдә тотуның төп сәбәбе – «хезмәт ияләрен дини сектантлык җәмгыятьләренә кушылудан саклау».

1950 елларда Дин эшләре буенча Советның урыннардагы Вәкиллекләргә җибәргән күрсәтмәләрендә мөселманнарның Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрен ничек уздыруларына, «изге урыннар, олылауга лаек каберлекләр» тирәсендә руханилар эшчәнлегенә игътибарны көчәйтергә, дингә ышанучыларны ураза тотарга, тәравих намазларына җәлеп итүнең яңа ысулларын ачыкларга һәм ислам эшлеклеләренең онытылган дини йолаларны торгызуга юнәлдерелгән гамәлләрен туктатырга тәкъдим итеЛә [Переписка с Советом... 1950 г., л. 12, 20].

БАССР мөселманнары арасында изге урыннарга табыну йолаларын үтәүнең авырлыгы дини

җәмгыятьләрне регистрацияләүнең катлаулылыгы, табыну урыннары – мәчетләрнең булмавы, беркайда да теркәлмәгән, «күчеп йөри торган» муллалар эшчәнлеге белән бәйле була. Изге урыннарга барып, регистрацияләнгән мәчетләрдә һәм рәсми дин әһелләреннән башка гына гыйбадәт кылу авыл җирлекләрендә киң таралган була. Чөнки шәһәрләрдә дини тормышны контрольдә тоту көчлерәк алып барыла. Табыну урыннары тирәсендә дини активлыкны киметү проблемасын хәл итү өчен авыл халкы арасында массакүләм мәдәни һәм сәяси чаралар оештыру көчәя. Изге урыннарга йөрүчеләрнең күп өлеше контрольгә алынмаганлыктан, дини тормышны республика күләмендә күзәтеп тору һәм тәртипкә салу эшендә кыенлыклар килеп чыга.

1954 елга Мөселман эшләре вәкиллегенең яртыеллык эш планы мөселман руханиларының исәптәге табыну объектлары тирәсендәге эшчәнлеген өйрәнүдән гыйбарәт була. БАССРда Мөселман эшләре вәкиллегенә түбәндәге эшләр тәкъдим ителә: «...путем выезда в Чишминский район изучить состояние религиозности мусульманского населения, деятельности зарегистрированных религиозных общин, групп верующих, действующих без регистрации, и мусульманского духовенства, обратив при этом особое внимание на изучение незарегистрированного духовенства и активность верующих вокруг почитаемой гробницы “Кашана”» [Переписка с Советом... 1954 г., л. 41]. 1958 елда СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенче Советка Вәкиллектән, БАССР территориясендә дин тотучы мөселманнар һәм руханилар тарафыннан аерым игътибарга лаек булган «изге урыннар» юк, дигән мәгълүмат бирелә. Шул ук вакытта регионда исламны тарату эшчәнлеге белән бәйле ике һәйкәл – Хөсәен бәк мавзолее һәм Тура хан мавзолее («Батыр» зираты) булуы аерып күрсәтелә. Әлеге документ авторы «В дореволюционный период паломничество “зиарата” Хусаин-бека принимало массовый характер, а за последние годы приток паломников в “зиараты” Хусаин-бека и “Батыра” значительно сократился, верующие мусульмане окрестных деревень посещают их группами и в одиночку в дни больших мусульманских религиозных праздников. В эти дни паломникам никто не препятствует, в среднем на каждом таком празднике бывает до 30 человек», – дип яза [Переписка с Советом... 1958 г., л. 31]. Дин эшләре буенча Советның БАССРдагы Вәкиллеге, СССР Фәннәр академисенең Башкортстандагы филиалында һәм Мәдәният министрлыгында әлеге объектларның фәнни өйрәнелеше хакындагы сорауларына алган җаваплардан соң, ул һәйкәлләрне алга таба өйрәнүгә ихтыяҗ юк, дигән нәтиҗәгә килә. Әлеге «төрбә» мөселманнар өчен «Изге урын» булып саналганлыктан һәм бу каберлекләр тирәсенә кешеләрне тарту белән рәсми теркәлгән яки теркәлмәгән руханилар эшчәнлеге күзәтелгәнлектән, Вәкиллек Хөсәен бәк белән Тура хан каберлекләрен

юкка чыгарып, мөселманнарның аларга зиярәт кылуларын туктатырга тәкъдим итә [Переписка с Советом... 1958 г., л. 31].

СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча советның 1958 ел, 10 декабрендә кабул ителгән «Изге урыннарга күмәкләп зиярәт кылуны туктату буенча чаралар турында»гы карары Вәкиллекнең дин эшлеклеләре күмелгән урыннарга йөрүне ачыклауга һәм бу гамәлне туктатуга юнәлдерелгән озак вакытлы эшләрен башлап җибәрә. БАССРдагы Вәкиллеккә дини үзәкләр һәм берләшмәләр җитәкчеләренең исемлеген булдыру, изге урыннарга зиярәт кылуны туктатуга кагылышлы мәсьәләләр буенча аларны чакыртып, аңлату һәм кисәтү эшләре йөкләнә [Переписка с Советом... 1958 г., л. 45]. СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча советның рәисе А.А. Пузинга Башкортстан вәкиллегеннән 1958 елның 27 сентябрендә юлланган язма хәбәрдә Чишмә районында Хөсәен бәк белән Тура хан төрбәләре булуы хакында тагын бер кат әйтелә. Анда, Хөсәен бәк кабере, җирле халык әйтүенә караганда, изге урын булып түгел, ә күренекле эшлекленең («зур начальникның») кабере генә булып санала, һәм мөселманнар, өлкән яшьтәге дин тотучылардан кала, анда даими йөрмиләр, фәкать мөселман бәйрәмнәрендә генә барып гыйбадәт кылалар, диелә. Вәкиллек әгъзасы фикеренчә, Тура хан кабере дә изге урын саналмый, анда дин тотучыларның зиярәт кылуы күзәтелми. Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Ш. Хиалетдинов белән әңгәмәдә бу объектларның изге урын буларак исәптә тормавы әйтелә. Төзелеш һәм архитектура академиясе мөхбир әгъзасы Б. Кәлимуллинның әлеге каберлекләрне Башкортстанның архитектур һәйкәлләре исемлегенә кертүе аларны юкка чыгарудан саклап кала [Переписка с Советом... 1958 г., л. 47–49].

«Изге урыннар»га даими зиярәт кылулар булмаса да, Вәкиллекнең кайбер әгъзалары тарафыннан Башкортстанда шундый ике-өч объект булуы исәпкә алына һәм 1959–1961 еллар дәвамында республикада зиратлар турындагы мәсьәлә берничә мәртәбә күтәрелә. Ул ислам дини эшлекләре күмелгән урыннарга барып гыйбадәт кылуны һәм дин әһелләренең Аллага ышанучыларны зиярәт кыларга оештыруларын саклап калу белән бәйле була. Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте мөфтиенең Вәкиллеккә җиткергән мәгълүматларына караганда, руханиларның дин тотучыларны Республикадан читтәге изгеләр каберләренә – Троицкидагы Зәйнулла ишан, Татарстан АССР, Ульяновск өлкәсе территорияләрендәге «Изге урыннар»га алып баруны даими оештырулары билгеләнә. Һәм моның төп сәбәбе итеп дини максат түгел, ә халыктан иганә (акча) җыю билгеләнә [Записи приемов Уполномоченным Совета... 1959 г., л. 2–3]. Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте тарафыннан дин

тотучыларны «Изге урыннар»га зиярәт кылырга чакырып берничә мөрәҗәгать әзерләнә. Дини эшләр буенча Совет Вәкиллеккә түбәндәге күрсәтмәне бирә һәм аны Диния Нәзарәтенә тәкъдим итәргә боера: «издать не обращение, а более расширенное толкование (фетву), провести ряд мероприятий: «проповеди в мечетях, беседы с духовенством и верующими, направленными не только на прекращение паломничества к зиаратам, но и по отношению различного рода бытующих среди мусульманского населения суеверий, которые используются различного рода шарлатанами в своих корыстных целях» [Переписка с Советом... 1959 г., л. 25]. 1959 елның 18 мартында бу күрсәтмә барлык мөхтәсибләргә һәм руханиларга җибәрелә.

СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Советның «Изге урыннар» белән көрәш буенча карары игълан ителгәннән соң Вәкиллек түбәндәге юнәлешләр буенча мәгълүмат әзерләргә тиеш була: «1. Общее количество выявленных на территории республики «святых мест и источников», к которым совершаются паломничества верующих; 2. количество «святых мест и источников», которые за отчетный период времени были закрыты и прекратили свою деятельность; 3. какими методами было прекращено паломничество к этим «святым местам и источникам»; 4. что конкретно намечено в отношении прекращения паломничества верующих к действующим в настоящее время «святым местам и источникам» (описать план намеченных мероприятий в отношении каждого действующего «святого места и источника»; 5. как были использованы возможности религиозных центров и глав церквей в деле прекращения паломничества к так называемым «святым местам и источникам» и какие дополнительные меры намечаются к дальнейшему использованию возможностей духовенства; 6. какую конкретную помощь оказывают Уполномоченные Совета руководящим органам республик и областей в развертывании массовой политической работы и научно-атеистической пропаганды среди трудящихся, имеющей целью показать обман пропаганды церковников и различных проходимцев о «святости» и «целебности» источников и т.д.; 7. на каком уровне, по сравнению с прошлым годом прошло паломничество верующих к действующим в настоящее время «святым местам и источникам» в частности по мусульманскому вероисповеданию в дни праздника ураза-байрам» [Переписка с Советом... 1959 г., л. 39–40].

Башкортстан Рспубликасы Үзәк тарихи архивында сакланган документлардан ачыкланганча, Вәкиллекнең «изге урыннар» белән көрәше 1960 еллар уртасына кадәр дәвам итә. Изгеләр каберлекләренә зиярәт кылуга каршы көрәшнең активлашуы ул объектларга якын җирлекләрдә яшәүчеләрнең дини гамәлләрен тиешле дәрәҗәдә контрольдә тота алмау белән бәйле була.

**Әдәбият**

Записи приемов Уполномоченным Совета по делам религиозных культов при Совете Министров БАССР представителей верующих и духовенства. 1959 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 21.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1944–1945 гг. // ЦИА РБ. Ф. Р-4732, Оп. 1. Д. 1.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1947 г. // ЦИА РБ. Ф. Р-4732, Оп. 1. Д. 3.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1950 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 6. Л. 12; ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 6.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1954 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 10 (II).

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1958 г. // ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 20.

Переписка с Советом по делам религиозных культов при Совете Министров Башкирской АССР. 1959 г. ЦИА РБ. Ф. 4732, Оп. 1. Д. 22.

***Хәбибуллина Зилә Рәшит кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, РФА Уфа Гыйльми үзәгенең*
*Р.Г. Кузеев исеендәге Этнологик тикшеренүләр институты*
*диннәр өйрәнү бүлеге фәнни хезмәткәре*